**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6258**
**24.09.2021**

Техник шартлар бирү турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкын су белән тәэмин итү һәм су бүлүне оештыру максатында «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 12 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 февралендәге 83 номерлы карары белән расланган Капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның техник шартларын билгеләү һәм бирү кагыйдәләренең 6, 7 пунктлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карары, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су бүлүнең үзәкләштерелгән системасы өчен гарантияләүче оешманы билгеләү турында» 2013 елның 13 июнендәге 3558 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә эшли торган гарантияләүче оешмага:

1) капиталь төзелеш объектларын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм су бүлү системасы челтәрләренә тоташтыруны техник шартлар белән тәэмин итү һәм шартлар бирү, транзит челтәрләре хуҗалары тоташтыруга техник шартлар бирүдән баш тартканда яисә бирелгән техник шартлар булмаганда;

2) транзит челтәрләре хуҗалары белән, законда билгеләнгән тәртиптә, бирелгән техник шартларны һәм тоташтыруга шартларны килештерергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И. С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. Ш. Салахов